ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне гамәлгә ашыру өлешендә мониторинглау нәтиҗәләре хакында

«Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне гамәлгә ашыру өлешендә мониторинглау нәтиҗәләре хакында Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Дәүләт корылышы һәм җирле үзидарә комитеты рәисе А.Г. Хәбибуллинның мәгълүматын тыңлап, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы КАРАР БИРӘ:

1. «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне гамәлгә ашыру өлешендә мониторинглау нәтиҗәләре хакында Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Дәүләт корылышы һәм җирле үзидарә комитеты рәисе А.Г. Хәбибуллинның мәгълүматын игътибарга алырга.

2. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Дәүләт корылышы һәм җирле үзидарә комитетына түбәндәгеләрне мониторинглау эшен дәвам итәргә:

«Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыруны;

Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы тарафыннан «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 40361-8 номерлы федераль закон проектын карау барышын.

3. «Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләр советы» ассоциациясенә Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Дәүләт корылышы һәм җирле үзидарә комитеты белән үзара эшчәнлектә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендә инициатив бюджет (инициатив

проектлар) турында норматив хокукый актлар нигезләмәләрен гамәлгә ашыру эшен дәвам итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Дәүләт корылышы һәм җирле үзидарә комитетына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе　　Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2024 елның 22 марты
№ 2385-VI ДС